| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ХОЗЕСАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19 ноябрь 2024 ел Хужа Хәсән авылы №8

Гражданнарнын үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Хужа Хәсән авыл
җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 29 ноябрендә 11 сәг 00 минутка Хужа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2024 елның 29 ноябрендә 16 сәг 00 минутка Хужа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. 2024 елның 30 ноябрендә 12 сәг 00 минутка Хужа Хәсән ав., Ольга Данилова ур., 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.

4. 2024 елның 30 ноябрендә 14 сәг 30 минутка Хужа Хәсән ав.,. Мәктәп ур, 23 йорт адресы буенча урнашкан Хужа Хәсән урта гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***дүртенче этабын*** билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районынын яшәү урыны урыны буенча Хужа Хәсән авыл җирлегенең Хужа Хәсән авыл территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю биналарын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районынын Хужа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хужа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева